№31, 13/IV 2005 ел

*1941–1945 Бөек Җиңүнең 60 еллыгына*

# Җиңү тылда да яуланды

Газстаның 16 март санында Флүрә Айдарованың «Без — сугыш ятимнәре» мәкаләсен укыгач, мин дә кулыма каләм алдым.

Мәрхәмәтсез сугыш безнең гаиләне дә читләтеп үтми. Әтинең колагы бераз ишетмәү сәбәпле, аны сугышка алмыйлар. Ләкин дошман Мәскәүгә якынлашкач, 1941 елның көзендә Оборона Комитеты карары белән күп халыкны Казанны әйләндереп алу өчен окоп казырга җибәрәләр. Бу вакыйга халык теленда окоп казу фаҗигаләре булып истә калган. Идел арьягында окоп казу өчен Иж-Бубый авылыннан да 91 кеше китә. Аларның күбесе хатын-кызлар була. Бертуган апасы Мәрьямне озата барган җиреннән әтине дә, авыру булуына карамастан, окоп казырга калдыралар.

Бу авыр хезмәттә зур газаплар күреп 90 авылдашыбыз авылга кире әйләнеп кайта. Ә безнең әти 1942 елның салкын гыйнварында каты авырудан шунда вафат була. Аны Апас районындагы бер авыл зиратына җирлиләр. Мәрьям апабыз кайткач, аның янына тезелешеп утырып: «Безнең әтине нигә алып кайтмадың?»—дип өзгәләнеп елаганыбыз әле дә хәтеремдә. «Әти» дип әйтергә тилмергән көннәр күп булды безнең. Ул вакытта иң өлкән апабызга — 13, иң кечкенә сеңлебезгә 5 яшь иде. Мәктәптә сыйныфташларым әтиләренең фронттан язган хатларын алулары турында куанып сөйләгәндә үзәкләремнең өзелгәнен язып кына аңлатып буламы соң?! Җитмәсә, югары сыйныфларда уку өчен елына — 150, югары уку йортлары өчен 400 сум түләргә кирәк иде. Ә окоп казучылар, сугышта катнашучылар исәбенә кермәгәнлектән, без ятимнәргә бернинди ташлама да булмады. Ничек кенә авыр булса да, әниебез 4 баласын кеше итү өчен тырышты. Ул — күптән инде гүр иясе. Хәзер үзебез дә — 70-80 яшьтә.

Мәктәп музеенда окоп казырга барган авылдашларның тулы исемлеге булмаса да, әниләре урынына окоп казыган 16 яшьлек Нәсимә Мусина һәм Тәскирә Гыйззәтуллинаның истәлекләре саклана. «Иске киез итек өстеннән чабата киеп товар вагоннарына утырып юлга кузгалдык. Безне Канаш станциясендә төшерделәр. Аннан җәяүләп Апас районына кадәр бардык. Һәр көнне лом, көрәк күтәреп 3-4 километр җәяүләп эшкә йөрдек. 30-40 градус суыкта бер ялсыз эшләдек. Көнгә 600 грамм ипи, сирәк кенә он, ярма бирәләр иде. Ә эштән кайткач, өстәге киемнәр белән сәндерәдә, идәндә тезелешеп йоклый идек», дип яза Нәсимә апа.

Окоп казуда катнашкан кешеләрнең батырлыгы, сугышта катнашучыларныкы кебек үк, ихтирамга лаек түгелмени? Тик нигәдер Җиңү көне уңаеннан ясалган чыгышларда окопчыларны беркем дә искә алмый. Бөек Җиңүнең 60 еллыгы якынлашкан көннәрдә безнең бәхетле киләчәгебез өчен тылда гомерләрен, сәламәтлекләрен кызганмаган әти-әниләребез, әби-бабайларыбызны да искә алыйк, аларның рухларын шатландырыйк. Алар моңа бик тә лаек.

*Рәмзия Хәлиуллина,*
*Иж-Бубый авылы.*

*13 апрель 2005 ел*

45